| | |
|---|---|
| СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
| 26.07.2018 | с. Нижний Услон | 49-193 |

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Уставы проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль Законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына, Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлегендә Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Советының 29.09.2017 ел, № 35-139 карары белән расланган ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Уставы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм аның өстендә эшне дәвам итәргә (1 нче кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Уставы проекты буенча керүче тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эшче төркем булдыру:

- эшче төркем рәисе, Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы Шәйдуллин А. З ;
- эшче төркем секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе Чемоданова Л. В ;

Эш төркеме әгъзалары:

- Сулейманова Наталья Викторовна-мәдәният йорты мөдире
- Морозенкова Нина Викторовна - авыл китапханәсе мөдире
- Иликов Виталий Владимирович Түбән Ослан мәктәбе укытучысы

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Уставы проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга. (Кушымта N 2).

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Уставы проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга (3 нче кушымта).

5. ТР Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Уставы проекты буенча ачык тыңлауларны 2018 елның 14 августында 10.00 сәгатьтә Түбән Ослан авылы, Завод урамы, 1а йорт адресы буенча үткәрергә.

6. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегендә яшәүчеләрнең тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Советына кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Советының социаль – мәдәни мәсьәләләр, Законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы. А.З. Шайдуллин